# КАРАР

## Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге составына керүче Югары Уратма торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2021 елның 13 ноябре                                                                                     № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 13 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге Югары Уратма торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

Бакча урамы буенча юлларны төзекләндерүгә (килешү буенча эшләр өчен түләү

ӘЙЕ                    ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 531 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар саны 268 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 268 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге составына керүче Югары Уратма торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип таныргa.
2. «Түбән Кама муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге Югары Уратма торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

Бакча урамы буенча юлларны төзекләндерүгә (килешү буенча эшләр өчен түләү

ӘЙЕ                    ЮК».

Мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Макаровка авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Макаровка авыл җирлеге башлыгы А.Н. Кудряшов